МЭР ГОРОДА
НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
ХАКИМЕ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

12 декабрь 2017 ел

№ М 483

Шәһәр Хакименең 2015 елның 31 декабрендәге М 415 нче карары белән расланган «Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы» исеме бирү турында нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.25 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Шәһәр Хакименең 2015 елның 31 декабрендәге М 415 нче карары белән расланган «Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы» исеме бирү турында нигезнамәгә, 1 нче кушымтаны кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башлыгы урынбасары Ф.И. Андреевага йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Яр Чаллы шәһәре Хакименең
2017 елның 12 декабрендәге
№ 483 нче карарына
кушымта

«Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы»
исеме бирү турында нигезнамә

1. «Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы» исеме гражданнарга шәһәр каршындагы аеруча казанышлары, шәһәр хуҗалыгының төрле өлкәләрендә шәһәрнең социаль-икътисадый үсеше бурычларын тормышка ашыруга керткән зур өлеше һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен бирелә.

«Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы» исеме бирү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) шәһәр данын арттыруга зур өлеш кертү;

2) озак еллар дәвамында хуҗалык, фән, мәдәният, мәгариф, шулай ук башка өлкәдә зур уңышларга ирешелгән эшчәнлек нәтиҗәсендә Яр Чаллы шәһәре халкында абруй казану;

3) нәтиҗәле мәдәни-агарту, иҗтимагый һәм хәйрия эшчәнлеге аркасында шәһәр халкы арасында озак вакытлы һәм тотрыклы танылу;

4) шәһәр һәм республика иминлеге хакына батырлыклар кылу.

2. «Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы» исеменә кандидатлар тәкъдим итү инициативасы белән дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, хезмәт коллективлары, иҗтимагый оешмалар чыгарга мөмкин.

3. «Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы» исеме бирү турындагы мәсьәләне карау өчен шәһәр Хакиме исеменә түбәндәге документлар тапшырыла:

- оешма җитәкчесенең имзасы һәм мөһер белән расланган юллама;
- бүләкләү кәгазе (2 нөсхә);
- бүләкләнүченең персональ мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы;
- юллама белән чыгучы коллектив җыелышының беркетмәсе;
- 3x4 үлчәмле төсле, ялтыравыксыз 2 фотосурәт.

Оешмалар җитәкчеләренә, аларның урынбасарларына, оешмаларның баш инженерларына, баш бухгалтерларына һәм баш икътисадчыларына өстәмә рәвештә түбәндәге документлар тапшырыла:

- салым түләүче (оешма) тарафыннан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пени һәм салым санкцияләре түләү буенча бурычлар үтәлеше турында салым инспекциясеннән белешмә;

- оешманың техник-икътисад күрсәткечләренең гомумиләштерелгән таблицасы (ФТЭПП 7.5.3.-01.);

- оешма хезмәткәрләренә хезмәт хакы буенча бурычы булмау турында белешмә.

4. «Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы» исеме «Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы» исеме бирү хакындагы тәкъдимнәрне карау

комиссиясенең тәкъдиме буенча Яр Чаллы шәһәре Хакименең карары нигезендә бирелә.

5. «Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы» исеме бирү хакындагы тәкъдимнәрне карау комиссиясенең рәисе һәм составы Яр Чаллы шәһәре Хакиме тарафыннан раслана.

6. «Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы» исеме бирелгән гражданнарга шәһадәтнамә, таныклык һәм күкрәк тамгасы Шәһәр көне алдыннан тантаналы рәвештә тапшырыла.

7. «Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы» исеменә лаек булган затларга, мактаулы граждан пенсия яшенә җиткәннән соң һәм шәхсән аның тарафыннан гариза бирелгән көннән башлап, Башкарма комитетның бухгалтерлык хисабы һәм хисаплылык бүлеге аша аларның банк учреждениеләрендәге счетларына акча күчерү юлы белән ай саен 1000 сум күләмендә акчалата түләү башкарыла. Әлеге ташламалар гаилә әгъзаларына кагылмый. Яр Чаллы шәһәренең мактаулы гражданына ташламалар бирү өчен акчалар чираттагы финанс елына шәһәр бюджетында карала.

8. «Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы» исеменә лаек булган гражданнар әлеге бүләк белән кабат бүләкләнә алмыйлар.

9. «Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы» исеме батырлык кылган, каһарманлык, кыюлык һәм тәвәккәллек күрсәткән өчен вафат булганнан соң да бирелергә мөмкин.

10. Бүләк (исем бирү турында карар, шәһадәтнамә, таныклык һәм күкрәк тамгасы) югалган очракта, бүләкләү турында карарның дубликаты «Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы» исеменә лаек булган гражданның гаризасы нигезендә, Башкарма комитет карары белән расланган Архив белешмәләре, архивтан өземтәләр, дәүләт милкенә караган һәм муниципаль архивта саклана торган архив фондлары буенча архив документларының күчермәләрен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына туры китереп бирелә.

Шәһадәтнамә, таныклык һәм күкрәк тамгасының дубликатлары бирелми.

11. Гаепләү турында суд карары үз көченә кергән очракта, Яр Чаллы шәһәре Хакиме «Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы» исеменнән мәхрүм итү хокукына ия.

12. «Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы» исеменә лаек булган гражданнарны исәпкә алу Шәһәр Советы тарафыннан расланган Яр Чаллы шәһәре бүләкләре турында нигезнамәгә туры китереп башкарыла.

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары

Ф.И. Андреева